СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

25.10.2022 с. Набережные Моркваши 25-154

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркврашы авыл җирлеге Яр буе Моркврашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркврашы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Яр буе Моркврашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022 елның 12 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркврашы авыл җирлеге Яр буе Моркврашы торак пункты территориясендә гражданнар арасында үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркврашы авыл җирлеге Яр буе Моркврашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез килешәсезме:

- Яр буе Моркврашы авылының Кәрим Тинчурин урамындагы җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. 13.00 сәгатьтә Яр буе Моркврашы авылы, Красавин ур., 40 йорт адресы буенча (Башкарма комитет бинасы) гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Яр буе Моркврашы авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркврашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов